РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул.Ленина, д.60,
с. Старый Мензелябаш, 423354
Телефон: (85559) 4-53-46
E-mail: Smnz.Sar@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ленин урамы, 60 йорт,
Иске Минзәләбаш авылы, 423354
Телефон: (85559) 4-53-46
E-mail: Smnz.Sar@tatar.ru

***ОКПО 04311866, ОГРН 1021601312237, ИНН/ КПП 1636001393/ 163601001***

# КАРАР

29.01.2015 ел № 5

## Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законының 15 маддәсе, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 22, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 20 маддәсенең 1 пункты, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставының 11,12 маддәләре, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында» 12.01.2015 ел №1 карары, Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының "Референдум үткәрү инициативасы турында»12.01.2015 ел №4 карары нигезендә Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. 2015 елның 15 мартына Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
I төркем инвалидлар, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар, көндезге уку йортлары студентлары, хәрби хезмәттә булган хәрбиләрдән тыш, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне:

-  җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруны;
- җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруны;
-  территорияне төзекләндерүне оештыруны;
-  җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм тормышка ашыруны
хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

ДА                                        НЕТ».

3. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән 5 көн эчендә мәгълүмат стендларына һәм авыл җирлегенең рәсми сайтына урнаштырып, игълан итәргә.
4. Карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш
авыл җирлеге Советы рәисе                                        А.Р. Мияссәрова